# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл жирлеге составына керүче Налим торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**20.11.2024** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 20 нче ноябрендә булып узган гражданнар җыены нәтиҗәләре нигезендә сорау буенча бе рketмә төзелде: "Сез 2025 елда Югары Налим авыл җирлегенең Налим торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 600 (алты йөз) сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә, көндезге формада белем алучы студентлардан, I төркем инвалидларыннан, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан т ыш, һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме:

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (беседканы китерү, җыю һәм урнаштыру (монтажлау); юлны вак таш белән ясау)."

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 55 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 37 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен 37 җыенда катнашучы тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен 0 җыенда катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлегенең Налим торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре-дөрес.

2. «Сез 2025 елда Югары Налим авыл җирлегенең Налим торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 600 (алты йөз) сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә, көндезге формада белем алучы студентлардан, I төркем инвалидларыннан, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, һәм алдагы эшләрне

башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме:

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (беседканы китерү, җыю һәм урнаштыру (монтажлау); юлны вак таш белән ясау).” - соравы буенча карарны кабул ителгән дип таныргa.

3. Карарны кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Югары Налим авыл җирлеге мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Югары Налим авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Югары Налим авыл җирлеге башлыгы Л.И. Сибгатуллин